

Тvбән Новгород олкәсендә 17-18 август коннәрендә сыерларны машина белән саву операторлары арасында 28 нче Ботенроссия һонәре буенча ин яхшысы конкурсы узды. Сыерларны машина белән савунын ин яхшы операторы исеме очен Россиянен 54 субъектыннан 63 катнашучы корәште.
Республика авыл хужалыгы һәм азык-толек министрлыгы хәбәр иткәнчә, Мордовияне әлеге конкурста Рузаевка районы «Стрелецк» җәмгыятьчелегендә эшләvче, әлеге һонәрдә 20 елдан артык хезмәт стажы булган Эдуард Сергеевич Александрин тәкъдим иткән.      Тәҗрибә һәм топ уныш– могезле малларны  тәр-бияләvче иргә карата мәхәб-бәт. Авыр хезмәт, әмма житештерv кvрсәткечләре - профессиональлекнен ачык дәлиле. Эдуард Сергеевич Александрин республикага бvләк белән кайтты. Үз категориясендә, ә ул – торле яшьтәге ир-ат савучылары («Мужчины всех возрастов») ярышларда мактаулы 3 урынны ала. Конкурста катнашучыларга дvрт этаптан узарга һәм vзләренен теоретик белемнәрен, саву аппаратын сvтvдә һәм жыюда осталыкларын, санитар әзерлекләрен, сыерларны савуда тәжрибәләрен кvрсәтергә тәкъдим ите-лә. Ярышларнын башыннан ук Эдуард Сергеевич лидерлар очлегендә була. Әмма финал этап-ларында якташыбыз Пермь краеннан килгән коллегасына оттырды.
Чараны ачу тантанасында Эдуард Александрин агросәнәгать комплексы системасында кvпьеллык намуслы хезмәте очен Россия Авыл хужалыгы министрлыгынын Мактау грамотасы белән бvләкләнә. Бvләкне Россия Федерациясе Авыл хужалыгы министры урынбасары Андрей Разин тапшырган.
Әйтеп китәргә кирәк, татар милләтле сыер савучы операторларыбыз Мордовиядә бар иде. Бvген бу профессия ир-атларга татымый.

**Н.ХӘЛИЛ**